**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 3 октябрь № 706

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 22 ноябрь, 909 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 22 ноябрь, 909 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 14 гыйнвар, 3 нче һәм 2015 ел, 12 февраль, 85 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пунктын өстәргә:

«$1^1$. Әлеге карар максатлары өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарына чираттагы финанс елының 1 гыйнварына кадәр гражданнар акчасын җәлеп итүне кертү турында җирле референдумнар (гражданнар җыеннары) үткәрергә тәкъдим итәргә.»;

әлеге карар белән расланган Гражданнар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибендә:

3 пунктка «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре» сүзләреннән соң «тиешле финанс елында бер тапкыр» сүзләрен өстәргә;

5 пунктның өченче абзацында «һәм күләмнәре» сүзләрен төшереп калдырырга;

5.1 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

6 пунктта:

беренче абзацта «30» саннарын «15» саннарына, «хисап ярты еллыгы» сүзләрен «агымдагы финас елының I кварталы» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «хисап чорында законнар нигезендә кабул ителгән карар күчермәсе» сүзләрен «агымдагы хисап елына кадәр булган елларда законнар нигезендә кабул ителгән карарлар күчермәләре» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «хисаптан өземтә» сүзләрен «хисаплардан өземтәләр» сүзләренә, «квартал» сүзен «чор» сүзенә алмаштырырга;

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлә);

2 нче кушымтада «квартал» сүзен «чор» сүзенә алмаштырырга;

3 нче кушымта үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2016\706.docx

Гражданнар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 3 октябрь, 706 нчы
карары редакциясендә)

Форма

Гражданнар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирүгә
заявка

________________________________________________
(муниципаль берәмлек исеме)
________________________________________________
(муниципаль берәмлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләсе исеме)

| Т/с | Чаралар исемлеге | Чараларны тормышка ашыруга акча, мең сум | Шул исәптән | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | кабат кабул ителгән карар буенча җәлеп ителгән гражданнар акчасы | бюджетара трансфертлар бирелмәгән элек кабул ителгән карарлар буенча җәлеп ителгән гражданнар акчасы | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | | | | | |
| | | | | | |
| Барысы | | | | | |

Муниципаль район, ______________/__________________________/
шәһәр округы башлыгы (имза) (имзаның аңлатмасы)
М.У.

____________________________________